РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

03.10.2022

№ 162-п

Рөхсәт ителгән төзелешнең чик
параметрларыннан читкә тайпылуга
рөхсәт бирү буенча ачык тыңлаулар
билгеләү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы нигезендә, В.Г. Шакирҗановның мөрәҗәгатен карап чыкканнан соң һәм халыкның ачык тыңлаулар аша фикер алышуда катнашу хокукларын яклау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. “Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Кызыл Мишә авылы, М. Җәлил урамы, 11а йорты (кушымта) адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында” Саба муниципаль районы Башкарма комитетының карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларның оештыручысы итеп Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссияне билгеләргә;

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. Ачык тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты - 2022 елның 4 ноябре, 9:00 сәгатьтә.

3.2. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Тимершык авыл җирлеге, Кызыл Мишә авылы, Ленин урамы, 32 йорт, Кызыл Мишә авыл мәдәният йорты.

3.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров урамы, 52 йорт, 105 бүлмә адресы буенча тапшырылырга мөмкин (эш көннәрендә 8:00 дән 16:30 га кадәр).

3.4. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 2022 елның 4 ноябре.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл

җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү Комиссиясенә:

– 2022 елның 4 октябренә кадәр әлеге карарны карар проекты белән бергә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Саба муниципаль районы рәсми сайтының (http://saby.tatarstan.ru) “Ачык тыңлаулар” бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

– Ачык тыңлаулар үткәрелә башлау турында халыкка Саба муниципаль районының рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) шулай ук Саба муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, шулай ук ачык тыңлауларда катнашучыларның күрсәтелгән мәгълүматка үтемлелеген тәэмин итә торган башка ысуллар белән хәбәр итәргә.Түбәндәгеләрне урнаштырырга:

1) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат, ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышы яки җыелышлары үткәрелү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат.

2) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат;

4) ачык тыңлауларда каралырга тиешле экспозициянең яисә проект экспозицияләренең ачылу урыны, датасы, мондый проект экспозициясен яисә экспозицияләрен уздыру вакыты, күрсәтелгән экспозицияне яисә экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) ачык тыңлауларда каралырга тиеш булган катнашучылар тарафыннан проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы турында мәгълүмат;

– карар проектын һәм аңа карата мәгълүмати материалларны “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында “Ачык тыңлаулар” бүлегендә урнаштырырга;

– 2022 елның 4 октябреннән алып 2022 елның 4 ноябренә кадәр ТР, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан Саба муниципаль районы Башкарма комитеты биналарында ачык тыңлауларда каралырга тиешле карар проекты буенча экспозиция ачарга һәм үткәрергә. Экспозицияне эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату, проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә (журналында) язылу юлы белән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү оештырылырга тиеш;

– ачык тыңлауларга әзерлекне, ачык тыңлауларда мәҗбүри рәвештә каралырга тиешле гражданнар һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә ;

– билгеләнгән вакыт нигезендә ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыруны тәэмин итәргә;

– ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

– ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне “Интернет” челтәрендә -Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтының “Ачык тыңлаулар” бүлегендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү Комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
2022 елның 3 октябрендәге 162-п
номерлы карарына
кушымта

“Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Кызыл Мишә авылы, М. Җәлил урамы, 11а йорты адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында” Саба муниципаль районы Башкарма комитетының карар проекты

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 һәм 40 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 14, 15 статьялары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре,беркетмә, ________________________________________________________ рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында карар һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. _____________________________________________________ ____________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан кадастр номеры ____ булган җир кишәрлегенә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирергә. Түбәндәгеләрне билгеләргә :

– җир кишәрлеге чигенең ян сызыгыннан корылмаларның минималь чигенеше (кадастр номеры ___ булган җир кишәрлеге ягыннан) - ________ м.;

– җир кишәрлеге чигенең ян сызыгыннан корылмаларның минималь чигенеше (кадастр номеры ___ булган җир кишәрлеге ягыннан) - ________ м.;

– кишәрлекнең арткы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше - _____ м.;

– катлар саны - ______ катлы.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны _______________________________________________ йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов